

Башка еллардан аермалы буларак, быел нәкъ чын кыш килде. Ә бит кыш- табигать фасыллары арасында ин салкыны. Алтын коз vтvгә, таягына таянып, ап-ак сакалын жирдән сойрәп кунакка кыш килә дә жир остенә кvбәләк-кvбәләк карлар яудыра, килә дә vзенен ак юрганын кырларга жәя. Якташ Һади Такташыбыз болай дип сvрәтли кыш-нын матурлыгын: “Ак чәчәкләр ява - донья матур!      Шундый матур булып тоела! Кvге зәнгәр – гvя йолдызлары, Ак кар булып жиргә коела.”

Матурга матур да бит, әмма быел кыш битләрне ошетердәй зәмһәрир салкыннарга да, кvз ача алмаслык бураннарга да бик бай иде. Авылларда, шәһәрләрдә кар оемнәре ой тvбәләрен ишелдертте, сукмакларны чистартканда йортлар биеклеге кар тау лары барлыкка килде – болар барысы да тормыш кондәлеге. Ә бит кышнын чын матурлыгын табигать кочагында гына тоярга була. Кышнын кояшлы коннәрендә кvзне камаштырган ап-ак кардан башка берни дә кvреп булмый, кvз чуала. Салкын коннәрдә агачларны vтә кvренмәле ап-ак ефәк белән чорнап алган агачлар бәс белән каплана. Агачка кагыласын да йомшак кына энже бортекләре коела, кышкы салкыннарда кәvсәләрене шартлаулары ишетелә. Пышылдап кына әйтелгән сvзләр дә еракларга янгырый. Чырык-чырык килгән чыпчыкларнын һәм гайбәтче саесканнын агачтан-агачка сикереп йорvе, тәрәзәгә жим сорап тукылдаган песнәкләр кышкы тормышка азмы-кvпме жанлылык орә. Ап-ак тvшәк остендәге эт, мәче, карга эзләре авылларнын ботенләй vк йоклап ятмавын кvрсәтә. Ә урманнар тагы да сихерлерәк кvренә: тирә-якта матурлык, аклык, сихри тынлык. Ботен доньяга яшәv матурлыгы турында кычкырасы килә. Тик тукталып каласын. Синен та-вышыннан агачлардагы ак-лык коелыр да, матурлыкка зыян килер кебек. Әлегә табигать, ягымлы язны котеп, тыныч кына йоклый…

Чv, йокламый, икән! Язнын беренче март ае керде: кояш ягымлырак яктырта, жил жиргә ятып ап-ак карны ашый, карлы янгырлар аяк астын шомарта... акны кара ясый. Котәбез, я тирә-якны суга батырып яз башы житәр, я ягымлылыгын кызганмыйча кояшыбыз карны эретер - кышнын сихри аклыгы китәр.

**Н.ХӘЛИЛ**